Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№33 (84)

24 октябрь 2013 ел

## • Вакыйгалар эзеннән

18 октябрь көнне Казан университеты тарихы музеенда **«КЕЧЕ БИЗНЕС ҺӘМ ГУМАНИТАР ФӘННӘР: ПРОБЛЕМАЛАР ҺӘМ АЛАРНЫ ЧИШҮ ЮЛЛАРЫ»** дигән темага түгәрәк өстәл оештырылды. Ул гуманитарийларга бизнес-предприятиеләр булдыру мәсьәләләренә багышланды. Чараны КФУның Хатын-кызлар лигасы иҗтимагый оешмасы үткәрде.

• • • •

КФУның чираттагы **РЕКТОРАТ УТЫРЫШЫ** 21 октябрь көнне узды. Аны ректор **И.ГАФУРОВ** алып барды. Чара «Шлюмберже Лоджелко, ИНК» стипендиясенә сертификатлар тапшыру белән башланып китте. Стипендия бер кешегә 45 мең сум тәшкил итә. Быел аны КФУда укучы 5 студентка бирделәр: Ю.Гарипова, М.Главатских, Д.Когогин, Р.Сидуллин һәм Г.Шакирова.

Аннан ректорат әгъзалары «Казан университетының атказанган хезмәткәре» мактаулы исемен Уку-укыту бүлегенең өлкән лаборанты Ф.Әсәдуллинага, укыту-методика эшләре буенча беренче категорияле белгеч Л.Леоновага һәм әйдәп баручы документовед Н.Мусинага бирүне хуплап кул күтәрделәр.

Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты директоры Р.Латыйпов Webometrics стрейтингының критерийларына статистик анализ үткәрде. Икътисад һәм финанс институты директоры Ш.Вәлитов брендлаштыру һәм университет брендын булдыру процессы хакында сөйләде.

• • • •

КФУда рус телле студентлар өчен алтынчы тапкыр **ТАТАР ТЕЛЕ** буенча вузара **СТУДЕНТЛАР ОЛИМПИАДАСЫ УЗДЫ**. Быел Филология һәм сәнгать институтына ТРның 9 югары уку йортыннан 120ләп катнашучы җыелды. Конкурс татар телен дәүләт теле буларак алга җибәрү, популярлаштыру, яшьләрдә татар халкының тарихи-мәдәни мирасына карата кызыксыну уяту максатында үткәрелә.

• • • •

22 октябрь көнне **КФУ** дөньяның төрле илләреннән **ЯШЬ ФИЗИКЛАР** һәм **МАТЕМАТИКЛАРНЫ КАРШЫ АЛДЫ**. Инде 16 ел рәттән уздырыла торган әлеге «Магнитлы резонанс һәм аның кушымталарының актуаль мәсьәләләре» Халыкара фәнни мәктәбе кысаларында университетыбызда магнитлы резонанс хакында фикер алышулар булды. Быел беренче мәртәбә когерент оптика һәм нанофотоника буенча секция эшләде.

• • • •

Кичә, ягъни **23 ОКТЯБРЬДӘ,** КФУның Кайгыртучанлык советы утырышлары залында «Фәнни җиһазлар һәм уникаль фәнни җайланмаларны коллектив куллану үзәкләренә дәүләт ярдәме: төп нәтиҗәләр һәм үсеш перспективалары» дип аталган **КОНФЕРЕНЦИЯ УЗДЫ**.

• • • •

**23 ОКТЯБРЬ** көнне Казан университетында фәнни эшчәнлек өлкәсендә **ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЛАРНЫҢ ЧЕЛТӘРЛЕ ТӘЭСИР ИТЕШҮЕ** мәсьәләсенә багышланган **КИҢӘШМӘ БУЛДЫ**. Анда һәр федераль университет вәкилләре үзләренең уку йортлары турында сөйләде һәм бу өлкәдәге эшчәнлекне дәвамлы итү буенча киңәшләре белән уртаклашты. Чара ике көн барды.

• • • •

Кичә ТРның Президент Аппараты инициативасы һәм ярдәме белән КФУның Дәүләт муниципаль идарә итүнең югары мәктәбе дәүләт хезмәткәрләре өчен **«ТР РАЙОН БАШЛЫКЛАРЫНЫҢ ИДАРӘ КОМПЕТЕНЦИЯСЕН ҺӘМ ҺӨНӘРИ ЯКТАН ӘҺӘМИЯТЛЕ КҮНЕКМӘЛӘРЕН ҮСТЕРҮ»** дигән квалификацияне арттыру курсларын ачып җибәрде. Программаны ачу тантанасында ТР Премьер-министры **И.ХАЛИКОВ**, КФУ ректоры **И.ГАФУРОВ** катнашты. КФУ базасында мондый курслар даими эшләп килә, ләкин район башлыкларының белемен арттыру беренче тапкыр башкарыла. Курслар ике сменада: 23-26 октябрьдә һәм 30 октябрьдән 2 ноябрьгә кадәр узачак.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Нәфис Сираҗетдинов фотосы

# Күңелдә һаман яз

Татарстанда бүген 120 дән артык милләт вәкиле һәм этник төркемнәр яши. Республикабыз халыклары, үзара бәйләнешләр нәтиҗәсендә өлкәләрдә бер-берсенә йогынты ясап, дус һәм тату тормыш итәләр. *Дәвамы 3 биттә.*

• Хезмәттәшлек

23 октябрьдә КФУ һәм «IRCICA» Ислам тарихы, сәнгате һәм мәдәнияте фәнни-тикшеренү үзәге арасында үзара килешүгә кул куелды. Аңа КФУ ректоры Илшат Гафуров һәм IRCICA генераль директоры Халит Эрен кул куйдылар.

# Мирасны танытабыз

Алинә САДЫЙКОВА


Влад Михневский фотосы

ИРСИКА (IRCICA) – ислам тарихын, мәдәниятен һәм сәнгатен өйрәнү буенча халыкара фәнни-тикшеренү үзәге. Ул Ислам конференциясен оештыруның мөстәкыйль органы булып тора. Конференция хәл итүе буенча, ислам фәнен үстерү һәм гуманитар бәйләнешләрне ныгыту максатыннан, 1980 елда оеша. ИРСИКА 35 илне берләштерә. Әлеге үзәк оештыра торган чаралар ислам мәдәниятен һәм цивилизациясен бөтен дөньяга танытырга ярдәм итә.

Ике арада төзелгән килешүнең төп максаты булып, тюркология, ислам тарихы һәм мәдәнияте, Шәрыкны өйрәнүнең төрле өлкәләрендә фәнни-мәгариф һәм мәдәни-мәгърифәтчелек багланышларын булдыру һәм үстерү тора. Ике як та фәнни мәгълүмат алышырга, тәҗрибә уртаклашырга, бергә төрле чаралар уздырырга, конференция-семинарлар үткәрергә әзер. КФУ һәм ИРСИКА арасындагы хезмәттәшлек шулай ук КФУ китапханәсе фондын ислам тарихы һәм мәдәнияте турындагы китаплар белән баетырга, КФУ белгечләрен үзәккә кульязмаларны өйрәнү өчен стажировкага җибәрергә мөмкинлек биреп, ИРСИКА белән берлектә «Мультимәдәни дөньяда ислам» конференциясен уздыруда, тарихи фотографияләр, каллиграфияләр күргәзмәләрен оештыруда һәм башка бик күп шундый максатларны тормышка ашыруда ярдәм итәчәк.

«ИРСИКА ислам мәдәнияте дөньясына ишекне ачарга ярдәм итә. Без Россиянең күп кенә фәнни оешмалары белән хезмәттәшлек итәбез. Менә бүген дә бу процессны киңәйтәбез. Әлеге проект Татарстанның бай мирасын башкаларга да күрсәтергә ярдәм итәчәк. Һәм, шул рәвешле, Татарстан республикасын, мәдәни мирасны һәм кульязмаларны саклау ягыннан ачып танытырга уңай шартлар тудырачак. Әлеге меморандум безгә, көчләрне берләштереп, фәнни кадрлар, фәнни тәҗрибә уртаклашырга җирлек тудырачак», – диде **Халит Эрен** үз чыгышында. ИРСИКА үзәге директоры Казан университетының мактаулы докторы булуы белән горурланганын әйтте һәм әлеге оешмада фәнни карьерасын тәмамлаганнан соң, КФУга ешрак килеп йөрергә сүз бирде.

Казан университеты ректоры үз чыгышында әлеге хезмәттәшлекнең интернационализация ягыннан әһәмиятлелегенә басым ясады: «Китапханәләребездә электрон версиягә күчерәсе әйберләр байтак, шуңа күрә әлеге проект безгә булган материалны кулланылышка кертергә генә түгел, ә яңа мәгълүматлар тупларга да ярдәм итәчәк. Диннәрне өйрәнү – бик озын һәм четерекле процесс. Хезмәттәшлек бу процессны бүтән югарылыкта башкарырга мөмкинлек бирәчәк».

Хезмәттәшлеккә кул куелганнан соң, ике як вәкилләре бер-берсенә бүләк бирештеләр. **И.Гафуров** ИРСИКА үзәге директорына шәһәребез турындагы китап һәм университет сувенирын тапшырды. Х.Эрен, үз чиратында, Стамбулдан алып килгән басмаларны бүләк итте.

• Бездә кунак бар

# «Әйдәгез, дус яшик!»

Раил САДРЕТДИНОВ, Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты


Влад Михневский фотосы

22 октябрь көнне Россия стратегик тикшеренүләр институты (РИСИ) җитәкчесе Леонид Решетников белән очрашу узды. Очрашуда күренекле тарихчылар, Дәүләт Советы депутатлары, Татар иҗтимагый үзәге вәкилләре, КФУ профессорлары һәм укытучылары, студентлар катнашты.

РИСИ – РФ президенты указы белән оештырылган эре фәнни-тикшеренү һәм аналитика үзәге. РИСИ оештыру турындагы указга 1992 елның 29 февралендә Россия президенты Б.Н.Ельцин кул куя, 2009 елның 29 апрелендә институт реформалаштырыла. Аның җитәкчесе итеп, Леонид Решетников билгеләнә. Институтның төп бурычы – РФ Президенты Администрациясен, Федерация Советын, Дәүләт думасын, Иминлек советын, Хакимият аппаратын, министрлыкларны һәм төрле идарәләрне мәгълүмати яктан тәэмин итү. РИСИ алда әйтелгән структура органнарына мәгълүмати-аналитик материаллар, эксперт бәяләмәләрен һәм тәкъдимнәрен җиткерә. Шулай ук РИСИ милли иминлек проблемалары, Россиянең башка илләр белән үзара мөнәсәбәтен тикшерү белән дә шөгыльләнә. Социаль-икътисади процессларның төбәктә һәм глобаль дәрәҗәдә ничек баруын күзәтә һәм анализлый, терроризмга каршы көрәшкә бик зур игътибар бирә, постсовет киңлегендә тарихи фактларның бозылуына каршы хәрәкәт алып бара.

Бу институтның төбәк үзәкләре Казан (2011 елдан бирле эшли), Калининград, Санкт-Петербург, Ростов-на-Дону, Владивосток, Екатеринбург, Иркутск шәһәрләрендә урнашкан. Чит илдә мәгълүмати-аналитик эшчәнлек институтның Болгария, Финляндия, Төркия, Франция илләрендәге вәкилләре тарафыннан башкарыла.

РИСИ, түгәрәк өстәлләр һәм конференция материалларына нигезләнеп, китаплар, монографияләр сериясен һәм РФнең югары аттестацион комиссиясе тарафыннан рецензияләнгән «Российский вектор», «РИСИның аналитик күзәтүләре» вакытлы басмаларын һәм «Милли проблема стратегияләре» исемле журнал нәшер итә.

Очрашуда Леонид әфәнде күп сорауларга җавап бирде. Аларның күбесе Татарстандагы дини һәм милли мәсьәләләргә багышланды, чөнки институтның төп өйрәнү мәсьәләләре дә шулар. «Татарстан бүген – Россия субъектлары арасында иң стабиль төбәкләрнең берсе. Әгәр Татарстан җимерелсә, Россия дә җимереләчәк. Без Татарстан өчен көрәшергә тиеш. Татарлар һәм руслар (башка милләтләрне кимсетү булмасын) Россиянең дәүләт төзүче халыклары булып тора. Чөнки Россия составына кергәнче, татарлар һәм русларның гына дәүләтләре булган. Татарлар – Россия өчен бастион, өмет ул. Шул мәгънәдә без, кешене күрә алмый торган исламны түгел, ә татар исламын, якты исламны күрсәтергә тиеш. Без мондый исламны бөтен Россия буенча ныгытырга тиеш. Россиядә моңарчы татар исламыннан башка ислам булмады һәм булырга тиеш тә түгел», – диде ул.

Очрашу ахырында Леонид Решетников бирегә җыелганнарның барысын да башка милләтләр белән үзара дус-тату яшәргә чакырды. Ул үз чыгышын совет мультфильмындагы Леопольдның афоризмга әйләнгән: «Давайте жить дружно!» – сүзләре белән тәмамлады.

• Чара

# Математик мәктәп

Илмир ВӘЛИЕВ,
Математика һәм механика институты

21 октябрь көнне «Гравитация һәм космология теориясендә сызыкча булмаган кырлар» Халыкара фәнни семинарының һәм «Фундаменталь объектларны һәм күренешләрне математикада һәм компьютерда модельләштерү» Бөтенрәсәй мәктәбенең ачылу тантанасы узды.

Әлеге семинар-мәктәп, GRACOS семинар-мәктәбенең традициясен дәвам иттереп, Н.И.Лобачевский ис. математика һәм механика институты базасында уза. Ачылу тантанасында сәламләү сүзе белән институт директоры В.Чугунов та катнашты. «Мондый семинар моннан ике ел элек үткәрелгән иде. Бу вакыт эчендә бик күп яңа мәгълүматлар, уй-фикерләр, ачышлар җыелгандыр. Бөтенрәсәй мәктәбе яшь математикларга, галимнәргә үсү һәм үз-үзләрен сынап карау мәйданы да булып тора».

Семинар-мәктәптә Ульяновск, Самара, Мәскәү, Белоруссия һәм башка чит төбәкләрдән килгән ике йөздән артык катнашучы тәҗрибә утраклашачак. Бу чараның максаты булып, яңа ачышлар, эшләр белән уртаклашу, гравитация, космология, астрофизика теорияләренә кагылган казанышларга анализ ясау тора. Программага килгәндә, ул бай һәм мавыктыргыч: яшь белгечләрнең лекцияләрен тыңлау, пленар утырышлар уздыру, килгән кунакларның докладлары буенча фикер алышу.

Бу көнне Белоруссиядән килгән профессор А.Минкевич **«Общие проблемы гравитационного взаимодействия»** темасы буенча чыгыш ясады. Шулай ук математика һәм механика институты доценты Е.Лихачев та бу өлкәгә кагылган эчтәлекле чыгышын тәкъдим итте.

Әлеге семинар-мәктәп алты көн дәвам итә. Аның ябылу тантанасы 26 октябрь көнне үтәчәк.




# Юбилеең белән!

22 октябрьдә Казан федераль университетында атнага ике тапкыр чыгып килә торган «Казанский университет» газетасына 85 яшь тулды!

Университетыбыз газетасының яше зур булса да, күңеле белән ул яшь һәм позитив, чөнки анда актив һәм тырыш кешеләр хезмәт куя. Газетаның коллективы зур түгел. Нибары сигез кеше безне иң соңгы яңалыклар һәм берсеннән-берсе кызыклы язмалар белән сөендереп тора.

Газетаның тарихы еракка барып тоташа. 1811 елда Россиянең иң беренче провинциаль газетасы булып саналган «Казанские известия» дигән газета чыга башлый һәм, күп тә үтми, әлеге басма Казан университетына бирелә. Университет газетасының рәсми туган көне 1928 елның 22 октябре дип игълан ителә. Нәкъ шушы көнне университет, студентлар һәм аның хезмәткәрләренең тормышын яктырта торган бу газета «На вузовской стройке» исеме белән чыга башлый. Бер елдан ул исемен «Ленинец» дип үзгәртә, ә инде 1992 елдан «Казанский университет»ка алмаштыра.

Еллар үтү белән, газетаның тиражы, укучылар саны арта, хәзерге вакытта бик популяр булган Интернет версиясе барлыкка килә. «Казанский университет»ның мактанырлык уңышлары байтак: ул, Россиякүләм һәм шәһәркүләм конкурсларда катнашып, призлы урыннар яулап тора.

Без дә хезмәттәшләребезне әлеге Юбилейлары белән тәбрик итәбез. Аларга иҗат уңышлары һәм озын гомер телибез.

• Тарих сәхифәләреннән

Мәгълүматны **Ләйсән ИСХАКОВА** туплады

# Тамырларыбыз уртак

Соңгы елларда Татарстанга Кытайдан килгән милләттәшләребез белән очрашырга, еш кына алар хакында газета-журналлардан укып белергә туры килә. Кайберәүләр аларны «кытай татарлары», ә икенчеләр «уйгыр татарлары» дип атый.



«Кытай татарлары» дигәне аңлашыла, чөнки алар Кытай җир легендә көн күрә. Ә уйгырлар белән милләттәшләребезне нәрсә бәйли соң? Иң элек уйгырларның кем икәненә төшенү урынлы булыр. Кемнәр соң ул уйгырлар? Әлеге халык белән татарлар арасындагы уртаклык нидән гыйбарәт? «Татар һәм уйгыр халыклары тарихта бергә булдылар, бабаларыбыз бергәләп зур дәүләтләр тоттылар, динебез, телебез уртак, каннарыбыз һәм ханнарыбыз уртак, язмышыбыз да бер төрле булды», – дип язды Фәүзия Бәйрәмова.

Төп уртаклык, әлбәттә, төрки халыклар булуыбызда. Уйгырстанга барып эләксәк, тел белмәүдән хафаланасы юк. Телләребездәге кайбер сүзләр уртак, икенчеләре исә охшаш. Шулай да сөйләшкәндә аермалар сизелә. Мисал өчен, җир – йәр, мизгел – мәзгил, биш – бәш, яңа – йәңи, син – сән, мин – мән дип әйтелә.

Хәзерге көндә Кытайның Уйгыр-Шенҗан автономияле төбәгендә 4 меңнән артык татар яши икән. Бу өлкәне тарихи яктан Көнчыгыш Төркестан дип тә атыйлар. XIX гасырның 30 нчы елларында илебездән киткән милләттәшләребез нәкъ менә шунда барып төпләнгән. Монда ул вакытта инде уйгырлар килеп, шәһәрләргә нигез салган була. Россиядәге инкыйлаб вакытында күчеп китүләр тагын да көчәя. Шул рәвешле татар һәм уйгыр халкы бергәләп яши башлый. XIX гасыр башында Уйгырстанга күченеп килгән татарлар уйгыр халкын мәгърифәтле иткәннәр, беренче уйгыр мәктәпләрен ачканнар. Аларда Зәйнәп Габитова, Гөләндәм Хәбибуллина кебек «мәгърифәт аналары» укыткан. Уйгыр-Шенҗан төбәгендә иң беренче татар мәктәбе Колҗа шәһәрендә төзелгән. Аны татар сәүдәгәрләре үз акчаларына торгызган һәм тоткан. Ул мәктәпкә хәтта Казаннан китаплар һәм укытучылар китерткәннәр.

Чынлыкта татарча укыту 1925 елдан кертелүгә карамастан, ул нибары 1936 елда гына рәсмиләштерелгән. Аның тарихы еракларга барып тоташа. 1868 елда Колҗа шәһәрендә мәдрәсә ачылып, 1871 елда ул мәктәпкә әверелә. Ераграк җирләрдән килеп укучы балалар өчен тулай торагы да була. Узган гасырның 50 нче еллары ахырында сәяси үзгәрешләр башлана һәм татарлар кабаттан туган җирләренә – Австралиягә, Америкага күчеп китә. Мәктәптә укытучылар калмый диярлек. Балалар саны да кими төшә. Шул сәбәпле, 1959 елның декабрь аенда татар мәктәбен ябарга мәҗбүр булалар. Әйе, татар мәктәбе ябылган, әмма аны җимермәгәннәр. Хәзер ул бинада Кытайдагы татарлар тормышын яктырткан музей оештырылган. Татарлар, берләшеп, мәктәп кенә түгел, ә үзләренең башка оешмаларын да булдыруга ирешә. Кытайда иң аз санлы милләт саналган татарның 78 профессоры бар. Бүген татар укытучылары хәтта кытай балаларына кытай грамматикасын өйрәтә. Милләттәшебез Борһан Шәһиди – кытай-татар сүзлеген төзегән галим, кытай телен кытайлардан да яхшырак белүче кеше.

Монда татарларга мәгърифәтле халыкка күрсәтелергә тиешле мөнәсәбәт булган, аларга һәрвакыт хөрмәт белән караганнар. Бүген дә шулай. Мәктәпләрдә һәм югары белем бирү системасында да шушы дүрт мең татарның зур бер өлеше эшли.

Шенҗан татарлары белән уйгырларны берләштерә торган тагын бер уртаклык – Ислам дине. Аларның да, безнеке кебек, ике зур бәйрәме бар: Ураза һәм Корбан бәйрәмнәре. Ураза бәйрәме тантанасы бик үзенчәлекле: бәйрәм иртәсендә мөселманнар мәчеткә барабан тавышына җыелалар икән.

Колҗа шәһәренең уртасында татар зираты бар. Ул тарихи урын булып исәпләнә. Әлеге урынны милләттәшләребез моннан бер гасыр элек сатып алган булганнар. Әлеге зират татарларның мәдәни мирасы буларак саклана. Димәк, тарихи ватаннарыннан еракта булуга карамастан, милләттәшләребез үзләрен бай тарихлы, мәдәниятле халык итеп танытуга ирешкән. Ләкин шунысы да мөһим: андагы хөкүмәт татар халкының бу рәвешле танылуын кабул итә, кимсетми.

Хәзерге вакытта бирегә яшәүче татарларда катнаш никахлар күп. Акрынлап уйгырлашу процессы бара, милләттәшләребезнең телләрендә инде уйгыр теленнән кергән алынмалар бик күп. Алар сөйләмнәрендә уйгыр сүзләрен татар сүзләре белән катыштырып кулланалар. Әмма бүген уйгыр мәктәпләре дә кытайлашу чорын кичерә. Шул сәбәпле, балалар үзара кытай телендә генә сөйләшә. Өлкән буын моңа бик хафалана, әлбәттә. Шуңа соңгы елларда яшь буынның белем алырга Казанга килүен гадәти хәл буларак кабул итәргә кирәктер. Милләттәшләребез өчен Казан тарихи-мәдәни Мәккәгә тиң.



**РИФКАТЬ ФӘХРЕТДИНОВ**, дүртенче буын кытай татары, Кытайның Уйгыр-Шенҗан автономияле төбәге

*«Хәзерге көндә безнең төбәктә татарча укыту бөтенләй юк. Шулай да якшәмбе мәктәпләре оештырыла. Кышкы, язгы каникулларда, балаларны җыеп, татарча укыталар. Гаиләдә татарча сөйләшүчеләр күп. Без сөйләшә торган татар теле үзенчәлекле. Аңа уйгыр теленең йогынтысы көчле. Шулай ук сөйләмебездә борынгы татар теле сүзләре шактый сакланган. Тукай шигырьләрендә очрый торган иске сүзләр бездә әле дә кулланыла. Бездә мөселман гореф-гадәтләре Татарстанга караганда яхшырак сакланган. Милли бәйрәм Сабантуй исә, Кытайның 4 шәһәрендә дәүләт ярдәме белән бик зурлап оештырыла. Анда татарлардан тыш уйгырлар, казахлар катнаша. Нәүрүз, Яңа ел бәйрәмнәрен дә бергәләшеп уздырабыз.*

*Без, татарлар, уйгырлар белән тугандаш мөнәсәбәттә яшибез. Уң күзем татар булса, сул күзем – уйгыр. Шәхсән үзем татар һәм уйгыр телләрен туган телләрем дип саныйм, ә кытай теле – дәүләт теле».*

• Авыл хәлләре

# Күңелдә һаман яз

**Раил САДРЕТДИНОВ,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

«Күңелдә яз булыр ул, урамда көз бит!» диярсең, дустым. Килешәм, ләкин җиһандагы көз күңелдә яз булганда күренми ул. Бәлки, яшь булып калуның сере дә күңелдә яз булудадыр…

Тирә-ягыбызда көзнең «кызган» мәле: сапсарыга төренеп утыра торган агачлар, аяк астындагы кечкенә йолдызларга тиң яфраклар, ашыкмыйча, тын гына күңелләргә үтеп керә торган көннәрнең илаһи моңы бөтен җиһанга ниндидер серлелек өсти сыман.

Көз фәлсәфи уйланулар өчен бер дигән вакыт булса да, сүзем Универсиада авылында узган чираттагы мәдәни чара – Этнофестиваль турында. Этнофестиваль Универсиада авылында инде икенче тапкыр үткәрелә. Чараны оештыручылар булып, Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты студентлары яши торган 18 йорт вәкилләре һәм аның педагог-оештыручысы – Нина Дорофеева тора.

Оештыручылар билгеләп үткәнчә, былтыр фестивальне Идел буе халыкларына гына багышлап үткәргән булсалар, быел аның географиясен киңәйтергә уйлаганнар: чарада дөньядагы барлык халыклар иҗатын, фольклорын, биюләрен күзәтергә, шул халык телендәге җырларны тыңларга мөмкинлек туды рылды.

Залга килеп керүгә, татарның елмаеп торган Шүрәлесе, рус фольклорыннан шалапай «Петруша», милли татар киемнәре кигән кыз белән егет каршы ала. Чарага бик яхшылап әзерләнгәннәр, анда ниләр генә юк иде: рус курчаклары, сәйләннән эшләнгән бизәнү әйберләре, сувенирлар, үрелгән челтәрләр, балчыктан эшләнгән фигуралар, картиналар... Болар барысы да студентлар хозурына тәкъдим ителде. Шул һөнәр белән шөгыльләнүче кешеләрне һәм аларның эшләнмәләрен һөнәрчеләр палатасыннан махсус чакырганнар. Шунысын әйтергә кирәк: студентларга һөнәрләр, эшләнмәләр бик ошады. Һәрбер күргәзмә өстәленең җитәкчесе (күбесе Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетында студентларга белем бирә) үз эшчәнлеге һәм эшләнмәләре турында бик тәфсилләп сөйләде һәм теләүчеләр өчен мастер-класслар оештыру мөмкинлеге турында әйтте.

Чыгышлар 4 номинациядә бәяләнде: вокал, бию, нәфис сүз, уен кораллары. Мәртәбәле жюри әгъзаларына кемне дә булса җиңүче итеп билгеләү ай-һай авыр булгандыр. Катнашучыларның һәрберсе – талантлы, иҗат уты белән янып торучы, күңелләрендә яз булган студентлар.







Нәфис Сиражетдинов фотолары

Тамашаны караганда, студентлар милли җыр-биюгә, башка милләтләрнең мәдәниятен өйрәнүгә сусаган икән дигән уй туйды. Чарада татар җырын ишетү, татар биюен күрү, татар шигырен тыңлау, татар халык уен коралы – курайдан чыккан көйләр белән хозурлану күңелгә рәхәтлек хисе өстәде. 8 йорттан Гөлчәчәк Мөхәммәтшина нәфис сүз номинациясендә, М.Җәлилнең «Вәхшәт» шигырен сөйләп, барлык кешенең күңелләрен тетрәндерде. Бу номинациядә беренче урын аңа биреләсе көн кебек ачык иде. 2 йорттан Регина Хисматуллина башкарган татар биюе, Алсу Шакирова (7 йорт) тарафыннан башкарылган «Ай, былбылым», Рузилә Исламова (15 йорт) башкарган «Гармун алыйк әле, дуслар» җыры, Регина Вәлиуллина (7 йорт) курайда уйнавы белән тамашачыларны таң калдырды.

Универсиада Авылында сервис оештыру бүлеге җитәкчесе Людмила Пигалева да, чыгышлар беткәннән соң, быелгы фестивальдән алынган хис-кичерешләре белән уртаклашты: «Н.Дорофеева тарафыннан оештырылган мондый фестивальдә катнашуым беренче тапкыр түгел. Миңа монда килүче кешеләрнең тамашачыга беренчел матурлыкны җиткерергә тырышулары ошый. Бүген дә катнашучыларның бөтен күңелен биреп чыгыш ясауларына сокланып утырдым. Монда һәркем йөрәге кушуы буенча килә, берәүне дә мәҗбүр итмиләр. Бу фестиваль бик тирән мәгънәгә ия!».

• Таныш бул!

# Нәселемнең тамырлары нык!

**Кадрия ХӘСӘНОВА,**
Гаммәви коммуникация
һәм социаль фәннәр институты

Бүген күп кенә яшьләр Америка дип «Ах!» иткәндә, Англиягә барырга хыялланганда, чит илгә чыгып, акча эшләргә ашкынып торганда, ул: «Туган иленнең ватанпәрвәре булырга кирәк! Казаныбызның үз рухын югалтуын теләмим!», – кебек тирән мәгънәле сүзләр сөйли, аларны дуслары белән уртаклаша һәм туган илле, туган шәһәрле булуы белән горурланып яши! Китаплар укырга, ихлас аралашырга, җырларга ярата. «Йолдызлык», «Морозко», «Сөембикә варислары», «Северное сияние» республика конкурслары лауреаты, «Татар кызы-2011» җиңүчесе. Рус һәм татар телләрендә иркен аралаша. Инглиз һәм гарәп телләрен үзләштерә. Ул үзен гап-гади татар кызы дип атый. Сүзем КФУның Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты студенты Ширин Аль-Анси хакында.

**– Синең исемең бик үзенчәлекле. Нәрсәне аңлата ул?**

- Ширин - фарсы телендә «баллы» дигәнне аңлата. Аны әти-әнигә дәү әнием тәкъдим иткән. (*Шириннең дәү әнисе - Татарстанның халык, атказанган артисты Гөлзадә Сафиуллина - К.Х.*).

**- Буш вакытыңны ничек уздырырга яратасың?**

- Укудан тыш вакытта мин фәлсәфә һәм психология фәннәре белән кызыксынам, махсус курсларга йөрим. Йога белән шөгыльләнәм. Китаплар укырга яратам.

**- Ә җырлавыңны син ничек атыйсың? Ул хоббимы?**

- Җырлаудан башка үземне күз алдына да китерә алмыйм. Ул - минем дөньям. Инде кечкенә чактан ук дәү әнием концертларында җырлый башлаган идем. Сәләт тә нәкъ менә дәү әнидән күчкәндер. Чөнки әти сәнгатьтән ерак кеше, ә әнием биюче минем.

**- Гаиләң белән дә таныштырып үт әле?**

- Без өч бала. Мин - уртанчысы. Абыем Омар - КДМУда беренче курста укый, ныклап торып фән белән шөгыльләнә. Минем иң зур ярдәмчем ул. Ә төпчегебез Морад беренче сыйныфта укый. Фортепианода уйнарга өйрәнә. Мин аңа икенче әни кебек инде (*елмая - К.Х.*). Кечкенәдән минем карамакта ул.



*Ширин 1993 елның 4 июнендә Йәмәндә дөньяга килгән. Минем әлеге исемне ишеткәнем юк иде. Дөресрәге, принцесса Ширинне беләм. Ә безнең үз Ширинебез дә бар икән бит!*

**- Күп кенә яшьтәшләребез бүген япон кухнясы белән кызыксына: суши, роллы ясарга өйрәнә. Ә менә Ширин нәрсәләр пешерергә ярата икән?**

- Нигә япон кухнясы? Безнең бит үзебезнең бик тәмле ризыкларыбыз бик күп! Ой, вакытым булганда, мин рәхәтләнеп төрле милли ризыклар пешерәм. Ә аеруча токмач басарга яратам. Дәү әнием пешергән пылауны аның кебек оста итеп әзерләргә өйрәнәм. Әниемнән гарәп сыйлары серенә төшенәм.

**- Әтиең - гарәп, әниең татар милләтеннән. Үзеңә кайсы милләт якынрак соң?**

- Мин үземне татар кызы дип саныйм. Тамырларымда гарәп каны агу көч бирә, әлеге ике милләт бер-берсен тулыландырып тора. Ике яктан да нәселемнең тамырлары нык! Ә менә ир туганнарым күбрәк гарәп милләтенә тартыла.

**- Киләчәктә синең тормыш иптәшең кайнар көньяк егете булачакмы, әллә?..**

- Әлбәттә татар булачак, иншаллаһ! (*Елмая - К.Х.*)

**- Син ялгызуйлану, ял итү өчен нинди урынны сайлыйсың?**

- Бик сирәк булгангамы, үземнең бүлмәм миңа дөньядагы иң тыныч урын булып тоела. Мин анда ял итәм, рәхәтләнеп җырлыйм, уйланам...

**- Ә башкалабызда син яраткан урыннар?**

- Миңа шәһәрнең үзәге, чор истәлекләре якын. Яз, җәй айларында су буенда йөрергә яратам, тыныч шәһәр урамнарын урау күңелемә рәхәтлек өсти. Казан туризм шәһәренә әверелмәсен, тарихи шәһәр булып калсын иде, дип телим мин!

**- Дусларыңны ничек сайлыйсың?**

- Инде беренче сыйныфтан ук без биш кыз гел бергә. Минем юлымда һәрвакыт яхшы кешеләр генә очрап тора, Аллаһка шөкер. Дусларым да, укытучыларым да...Дусларым - чын мәгънәсендә чиста күңелле, саф татар балалары. Моның белән чиксез горурланам һәм шатланам. Бөтен кешегә дә бәхет телим!

**Менә шундый сәләтле дә, инсафлы да, нәкъ татар кызларына хас булганча тыйнак һәм сабыр да ул Ширин! Кап-кара озын чәчле, матур итеп татарча сөйләшә белүче кыз! Әйе, чын татар кызы ул Ширин!**

• Аклы-каралы дөнья

# Эквадор кунаклары

**Раил САДРЕТДИНОВ,** Гаммәви коммуникация
һәм социаль фәннәр институты

Якшәмбе... Бауман урамы буйлап атлыйм. Кеше һәрвакыттагыча күп. Кемдер минут саен арта барган халык шаукымына ера-ера каядыр ашыга, чаба, кемдер тирә-ягындагы бина фасадларына сокланып, салмак кына ләззәтләнеп атлый. Урамның бер башыннан (Г.Тукай метро станциясе ягыннан) әллә нинди сәер көй агыла. Әйе, бу гадәти генә көй түгел, уйландыра да, күңелнең әллә кайсы төшләренә үтеп тә керә торган көй. Ул көйне якынрак килеп тыңлыйсы, кабат-кабат ишетәсе килә. Үзем тыңлыйм, үзем һаман шул көйгә якынаям.

Музыкантларны уратып алган халык төркеменә килеп кушылуга, музыкантларның Эквадор дәүләтеннәнкилгән кунаклар – чын индеецлар булуына төшендем. Кунакларның Казанда ничәнче чыгыш ясавыдыр – төгәл санын әйтеп булмый, ләкин шунысы төгәл билгеле: алар яныннан беркайчан да халык өзелми, ә арта гына бара. Бергә фотога төшәләр, уйнаган төрле көйләрен видеога яздыралар. Кунаклар үзләре алып килгән сувенирлар белән сату итә.

Шаккатмаслыкмыни?! Үзләренең милли киемнәреннән, милли уен кораллары ярдәмендә төрле көйләр чыгаручы индеецларны Россиянең урта бер җирендә урнашкан Казанда күргәч, нигә әле бу форсаттан файдаланмаска ди! Кеше бит ул эчке халәте буенча сәяхәтче, романтик. Аңа һәрвакыт ниндидер яңалык, ниндидер экзотика кирәк. Бу очракта да шулай. Үзебезнең милли киемнәрне киеп, милли уен коралларыбызны тотып, Бауман урамына концерт куярга чыксак, татарларның кем икәнлекләрен белеп бетермәгән туристлардан кала, беркем дә туктап карап тормаячак бит?!

Төркемнең һәр кешесе – профессиональ музыкант. Уен коралларының да кайберләрен үзләре ясаган, ә киемнәре – Эквадор фабрикасыныкы икән, ләкин элек мондый киемнәрне ата-бабалары кулдан эшли торган булган. «Кан кардәшләр» группасы тарафыннан башкарылган һәрбер җыр билгеле бер мәгънәгә ия. «Бизнес Online» Интернет газетасына биргән интервьюларында алар: «Без этник музыка уйныйбыз. Ата-бабаларыбыз рухын хөрмәт итәргә, кояшка, Җир-Анабызга, суга, һавага рәхмәтле булырга кирәклеге турында җырлыйбыз. Безнең һәрберебез җыр яза», – диләр.

Галимнәр кешелек тарихы Африка кинләкләреннән башланган, диләр. Индеецлар башкарган һәр композиция шуның бер мисалы булып тормыймы соң? Алар уйнаган көйләр яшәешебез, тормыш турында уйланырга мәҗбүр итә, күңелгә үтә дә бер шом сала. Әйтерсең лә, күңелебезгә ул көйләрне укый торган матрица урнаштырганнар.



Кунаклар күңеленә башкалабызның киң урамнары, матур биналары, татар милли ашлары хуш килгән.

Үзләре исә Казаныбызның тыйнак кына бер хостелендә урнашканнар. Эквадор кунакларының быелгы йомгаклау концерты ай ахырында узачак. Тик бу аларның соңгы килүләре булмас дип ышанасы килә.

• Безнең канат

# Тарих белән кызыксынабыз

КФУның Н.И.Лобачевский исемендәге
лицееның **8 С сыйныфы укучылары**

Н.И.Лобачевский исемендәге лицей укытучылары безнең лицей тормышын тагын да мавыктыргыч һәм кызыклы итәр өчен, төрле чаралар уздыра.

Шушы көннәрдә без Казан университеты тарихы музеена сыйныф белән экскурсиягә бардык. Музейга керүгә үк, бинаның күз явын алырлык матур, мәһабәт икәнен күреп таң калдык. Кайбер музейларга керсәң, күңелне ниндидер шом били ала. Ә монда бар да башкача. Зур зал, анда ни генә юк. Һәр экспонаттан белем нуры бөркелеп тора.

Экскурсовод әйткән һәр сүзне мавыгып тыңладык, чөнки Казан университеты тарихы, анда укып, зур уңышларга ирешкән, бөтен дөньяга танылган галимнәр турында күбрәк беләсебез килә иде. Ике гасырдан артык тарихы булган уку йортында зур шәхесләр белем алган. Безнең лицей бөек математик Н.И.Лобачевский исемен йөртә, аның турында без бик күп кызыклы мәгълүматлар ишеттек. Химиклар К.К.Клаус, А.М.Бутлеров, Антарктиданы ачкан астроном И.М.Симонов һәм башка бөек шәхесләрнең шәхси әйберләрен күрә алдык. Бөек Ватан сугышына багышланган экспонатлар игътибарыбызны аеруча җәлеп итте. Уку йортының бүгенге көненә багышланган күргәзмәләрне дә бик теләп карадык.

Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк, диләр. Ә без – киләчәк. Шушы бай тарихлы, күркәм традицияләре, шул ук вакытта күп яңалыклары булган, заманча уку йортында – Казан федераль университетында уку теләге тагын да артты. Без дә зур галимнәр булырга, төрле ачышлар ясарга телибез. Шушындый кызыклы, эчтәлекле экскурсия оештыручылары өчен, лицей укытучыларына, экскурсоводларга зур рәхмәт сүзләрен җиткерәбез.

DARELFӨNYN университет
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълумати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ЖҖҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.